## «Без татарча укыйбыз!» видеороликлар бәйгесенең нәтиҗәләре

Яр Чаллы китапханәләр системасының 12нче санлы татар китапханәсе **1 февральдән 18 апрельгә** кадәр **«Без татарча укыйбыз!»** дигән шәһәркүләм видеороликлар бәйгесе үткәрде.

Бәйге татар китабын визуаль культура чаралары кулланып пропагандалау һәм популярлаштыру максаты белән үткәрелде.

Бәйгедә 7-16 яшьтәге балалар катнашты.

Бәйгенең җиңүчеләре:

1 урында – 34 нче мәктәп укучысы Ахунов Әмир
(җитәкчесе Мухаметдинова З.М.).

2 урында – 60 нчы мәктәп укучысы Шәкүрова Әдилә
(җитәкчесе Назипова А.Ф.).

3 урында – 86 нчы «Өмет» интернат мәктәбе укучылары Сабирова Аделина, Фардеев Рамис, Филиппов Данил (җитәкчеләре Гареева Л.М.).

Бәйгедә катнашкан барлык укучыларга, укытучыларга, әти-әниләргә рәхмәтебезне белдерәбез, иҗади уңышлар телибез!